КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 ноябрь г.Казань № 1028

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре һәм диагностика картасы дубликатын кәгазь чыганакта биргән өчен түләү күләмнәре үтәлешенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 2 декабрь, 1279 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 июль, 861 нче, 2023 ел, 20 декабрь, 1651 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре һәм диагностика картасы дубликатын кәгазь чыганакта биргән өчен түләү күләмнәре үтәлешенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы төрен үткәрү һәм сайлау турында карар кабул иткәндә зыян (зарар) китерү куркынычын бәяләү максатларында мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары билгеләнә:

шул ук чор өчен техник тикшерү үткәрелгән транспорт чаралары саны саклanган вакытта үткән календарь ел белән чагыштырганда календарь елга транспорт чараларының һәр категориясе яктылыгында техник тикшерүдән һәм диагностика картасы дубликатын кәгазь чыганакта бирүдән керә торган табышны ике һәм аннан күбрәк тапкырга арттыру яки аны иң күбе 5 процентка арттыру;

контрольдә тотыла торган затка карата «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган белешмәләрне җыю һәм анализлау юлы белән үткәрелгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү нәтиҗәләре буенча

Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән исәп-хисап счетында диагностика картасы дубликатын биргән, транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән, кәгазь чыганакта диагностика картасы биргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән өчен түләү билгеләү транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең билгеләнгән күләмен арттыру факты,

узган календарь ел белән чагыштырганда контрольнең бер объектына карата ел дәвамында контроль органы тарафыннан бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турындагы кисәтүләр санын арттыру.»;

13 пунктта «куркыныч индикаторы» сүзләрен «куркыныч индикаторлары» сүзләренә алмаштырырга;

45 пунктның дүртенче абзацында «куркыныч индикаторы» сүзләрен «куркыныч индикаторлары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 921 нче карары белән расланган Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 21 ноябрь, 1238 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 июль, 861 нче, 2023 ел, 21 декабрь, 1658 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Тормыш өчен кирәкле һәм бик мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне куллануны төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы төрен үткәрү һәм сайлау турында карар кабул иткәндә зыян (зарар) китерү куркынычын бәяләү максатларында мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары билгеләнә:

яшәү өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән шундый ук чорда сатылган дару препаратлары санын саклаганда яки аның артуы 5 проценттан артмаганда алдагы календарь ел белән чагыштырганда календарь ел өчен яшәү өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын сатудан тулаем табышны ике тапкырга һәм аннан да күбрәк тапкырга арттыру;

контрольдә тотыла торган затка карата «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган белешмәләрне җыю һәм анализлау юлы белән үткәрелгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү нәтиҗәләре буенча, сатып алу бәяләренең һәм (яисә) яшәү өчен кирәкле һәм иң мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына отпуск ваклап сату бәяләренең һәм (яисә) иң чик ваклап сату бәяләренең күләмнәрен арттыру факты буенча билгеләү;

контрольнең бер объектына карата узган календарь ел белән чагыштырганда контроль органы тарафыннан бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турындагы кисәтүләр санын арттыру.»;

13 пунктта «куркыныч индикаторы» сүзләрен «куркыныч индикаторлары» сүзләренә алмаштырырга;

45 пунктның дүртенче абзацында «куркыныч индикаторы» сүзләрен «куркыныч индикаторлары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин